ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29 март 2019г. № 1607

Башкарма комитетның «2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә террорчылык һәм экстремизмны профилактикалау, шулай ук террорчылык һәм экстремизм күренешләре нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яки) бетерү» муниципаль программасын раслау турында» 2016 елның 3 ноябрендәге 5794 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, шәһәр Уставының 41 маддәсе, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 нчы карары нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәре территориясендә террорчылык һәм экстремизмны профилактикалау, шулай ук террорчылык һәм экстремизм күренешләре нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яки) бетерү» муниципаль программасын раслау турында» 2016 елның 3 ноябрендәге 5794 нче карарына (Башкарма комитетның 2018 елның 29 мартындагы 1693 нче, 2018 елның 20 ноябрендәге 6829 нчы, 2018 елның 25 декабрендәге 7763 нче карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән программаны финанслауны Яр Чаллы шәһәре бюджетының «Гомумдәүләткә караган башка мәсьәләләр» 01.13; «Мәктәпкәчә белем бирү» 07.01; «Гомуми белем бирү» 07.02; «Яшьләр сәясәте» 07.07 бүлекләрендә (бүлекчәләрендә) каралган акчалар хисабына 2017 елда – 11907,5 мең сум, 2018 елда – 12097,7 мең сум, 2019 елда – 13478,4 мең сум күләмендә тәэмин итәргә.»;

2) «2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәре территориясендә террорчылык һәм экстремизмны профилактикалау, шулай ук террорчылык һәм экстремизм күренешләре нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яки) бетерү» муниципаль программасында:

- 1 бүлектә «Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | Финанслау чыганагы | Программаны тормышка ашыру еллары | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2017 ел мең сум | 2018 ел мең сум | 2019 ел мең сум | Тормышка ашыру чорында барлыгы мең сум |
| | Муниципаль бюджет | 11907,5 | 12097,7 | 13478,4 | 37483,6 |
| | Федераль бюджет | - | - | - | - |
| | Республика бюджеты | - | - | - | - |
| | Башка чыганаклар | - | - | - | - |
| | Барлыгы | 11907,5 | 12097,7 | 13478,4 | 37483,6 |

- 5 бүлекне кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә;

- 6 бүлекнең 8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. 2017-2019 елларга программаны финанслау күләме 37483,6 мең сум тәшкил итә.

Программаны финанслау чыганагы булып Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты тора.

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең бюджет акчалары:

чор өчен барлыгы 37483,6 мең сум, шул исәптән программаны тормышка ашыру еллары буенча: 2017 елда – 11907,5 мең сум, 2018 елда – 12097,7 мең сум, 2019 елда – 13478,4 мең сум.»

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2019 елның 29 мартындагы
1607 нче карарына
кушымта

## 5 бүлек. Программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм программа чараларын финанслау

| Т/с | Төп чараларның исеме | Башкаручы | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторы, үлчәү берәмлеге | Индикаторларның зурлыгы | | | | Финанслау чыганагын күрсәтеп финанслау (мең сум) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | база | 2017 | 2018 | 2019 | 2017 | 2018 | 2019 |
| Максат: террорчылык һәм экстремизмны кисәтү системасын камилләштерү, халыкның, Яр Чаллы шәһәре территориясендә урнашкан белем бирү оешмаларының мөмкин булган террорчылык гамәлләреннән саклану дәрәҗәсен күтәрү | | | | | | | | | | | |
| | | | | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә террорчылык актлары кылу (кылырга тырышу) берәмлек | 0 | 0 | 0 | 0 | | | |
| 1 бурыч. Халык белән террорчылык һәм экстремизм эшчәнлеген кисәтүгә юнәлдерелгән тәрбия, пропаганда эшләре үткәрү | | | | | | | | | | | |
| 1 | Яшьләр мохитендә экстремизмны профилактикалау һәм позитив тормыш кыйммәтләре | Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе, «Диалог» | ел саен | бер төрдәге методик кулланмалар (данә) | 81 | 80 | 80 | 80 | Муниципаль бюджет | | |
| | | | | | | | | | 20,0 | 20,0 | 20,0 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | формалаштыру буенча белгечләр өчен методик кулланмалар һәм мәгълүмати материаллар бастырып чыгару | психологик-педагогик ярдәм үзәге» МБУ | | листовкалар (данә) | 300 | 300 | 200 | 200 | | | |
| | | | | буклетлар (данә) | 300 | 300 | 200 | 200 | | | |
| 2 | Массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртып, дини конфессияләр, милли берләшмәләр вәкилләре катнашында чаралар оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитет мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсенең җәмәгатьчелек белән элемтә бүлеге, Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге | ел саен | чаралар саны, берәмлек | 4 | 4 | 4 | 4 | финанслау таләп ителми | | |
| 3 | Башкарма комитет карамагындагы дини һәм иҗтимагый оешмалар белән үзара эшчәнлек буенча совет утырышларын оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитет мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсенең җәмәгатьчелек белән элемтә бүлеге | квартал саен | чаралар саны, берәмлек | 4 | 4 | 4 | 4 | финанслау таләп ителми | | |
| 4 | Төрле максатчан аудиторияләр өчен экстремизмны профилактикалау һәм толерантлык формалаштыруга юнәлдерелгән лекторийлар, семинарлар үткәрү | «Диалог» психологик-педагогик ярдәм үзәге» МБУ | ел саен | чаралар саны, берәмлек | 6 | 6 | 6 | 6 | финанслау таләп ителми | | |
| 5 | Милли диаспораларны халык белән террорчылык һәм экстремистик эшчәнлекне кисәтүгә юнәлдерелгән тәрбия эшләре үткәрүгә җәлеп итү | Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе, Башкарма комитетның | квартал саен | чаралар саны, берәмлек | 4 | 4 | 4 | 4 | финанслау таләп ителми | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | мәдәният идарәсе, «Чишмә» халыклар дуслыгы йорты» МАМУ | | | | | | | | | |
| 6 | Белем бирү оешмаларында түбәндәгеләрне үткәрү:<br>- милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр өлкәсендәге закон нигезләрен аңлату буенча дәресләр;<br>- этникара һәм динара килешү шартларында яшәү ихтыяҗларын формалаштыру һәм ныгыту максатында укучыларның актив катнашу формаларына юнәлдерелгән чаралар (рольле уеннар, конкурслар һ.б.)<br>- укучыларда милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрдә толерантлыкны үстерүгә юнәлдерелгән сыйныф сәгатьләре | Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе | уку елы дәвамында | чаралар саны, берәмлек | 2<br>2<br>2 | 2<br>2<br>2 | 2<br>2<br>2 | 2<br>2<br>2 | финанслау таләп ителми | | |
| 7 | Яр Чаллы шәһәре һөнәри белем бирү оешмаларының һәм югары белем бирү оешмаларының студентлары арасында террорчылыкка һәм экстремизмга каршы тору проблемалары буенча тикшеренү эшләренә һәм проектларына конкурс оештыру | Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе, «Нур» яшьләр үзәге» МАУ | 2017-2019 еллар | бүләкләнү чеәр саны (бүләкләрне финанслау), кеше | 6 | 6 | 6 | 6 | Муниципаль бюджет | | |
| | | | | | | | | | 18,0 | 18,0 | 18,0 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 8 | Террорчылыкны, экстремизмны профилактикалау буенча буклетлар, плакатлар эшләү һәм әзерләү, белешмәлекләр һәм календарьлар тарату | Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге | 2017-2019 еллар | буклетлар әзерләү, данә | 500 | 500 | 300 | 300 | Муниципаль бюджет | | |
| | | | | плакатлар әзерләү, данә | 500 | 500 | 300 | 300 | 31,9 | 26,8 | 32,0 |
| | | | | белешмәлек ләр әзерләү, данә | 500 | 500 | 300 | 300 | | | |
| | | | | йорт рәвешендәге календарь лар әзерләү, данә | 500 | 500 | 300 | 300 | | | |
| 9 | Республика һәм федераль дәрәҗәдә оештырылган, террорчылык һәм экстремизмны профилактикалау мәсьәләләренә багышланган яшьләр форумнарында катнашу | Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе, «ФОРПОСТ» ҖТС(я)ФҮ» МБУ, Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге | ел саен | чаралар саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | финанслау таләп ителми | | |
| 10 | Экстремизм һәм террорчылык маддәләре буенча хөкем ителеп, иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән куркыныч төркем затларының мәгълүматлар банкын актуальләштерү | Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге, террорчылыкка каршы комиссия | кирәк булган саен | куркыныч төркем затларының мәгълүматлар банкын актуальләш терү саны, берәмлек (кирәк булганда) | | | | | финанслау таләп ителми | | |
| 11 | Яшүсмерләр һәм яшьләр мохитендә экстремизмны профилактикалау һәм толерантлык формалаштыру өлкәсендә эш оештыру буенча яшьләр сәясәте | «Диалог» психологик-педагогик ярдәм үзәге» МБУ | ел саен | чаралар саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | финанслау таләп ителми | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | белгечләренең методик берләшмәсенең эше кысаларында тематик семинарлар үткәрүне тәэмин итү | | | | | | | | |
| 12 | Яшьләрдә толерантлык аңын үстерүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрү | Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе, «Диалог» психологик-педагогик ярдәм үзәге» МБУ | ел дәвамында | чаралар саны, берәмлек | 4 | 4 | 4 | 4 | финанслау таләп ителми |
| 13 | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 25 мартындагы 272 нче карары нигезендә кешеләр күпләп җыела торган урыннар реестрын актуальләштерү | Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге, Башкарма комитетның структур бүлекчәләре | кирәк булган саен | чаралар саны, берәмлек | - | - | - | - | финанслау таләп ителми |
| 14 | Комиссия тарафыннан кешеләр күпләп җыела торган урыннарны террорчылык актларын кисәтү һәм профилактикалау, террорчылыкка каршы саклану предметына тикшерү | Кешеләр күпләп җыела торган урыннарны тикшерү буенча ведомствоара комиссия, террорчылыкка каршы комиссия | кирәк булган саен | чаралар саны, берәмлек | - | - | - | - | финанслау таләп ителми |
| 15 | Муниципаль берәмлек территориясендә террорчылыкка каршы тору мәсьәләләре буенча террорчылыкка каршы комиссия утырышы үткәрү | Террорчылыкка каршы комиссия | квартал саен | чаралар саны, берәмлек | 4 | 4 | 4 | 4 | финанслау таләп ителми |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 16 | Шәһәр сайтында «Террорчылык актлары барлыкка килү куркынычы янаганда эш итү тәртибе турында» белешмәлекләр, мәгълүматлар урнаштыру | Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге | ел дәвамында | чаралар саны, берәмлек | 2 | 2 | 1 | 1 | финанслау таләп ителми |
| 17 | Барлык тип массакүләм мәгълүмат чараларында террорчылыкка һәм экстремизмга каршы торуда халыкның актив катнашуына булышлык итүче тематик рубрикалар чыгаруны гамәлгә ашыру | Башкарма комитет мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсенең массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү бүлеге | ел дәвамында | чаралар саны, берәмлек | 3 | 3 | 3 | 3 | финанслау таләп ителми |
| 18 | Шәһәрнең рәсми сайтында төрле конфессияләргә, традицион мәдәни рухи кыйммәтләргә һәм дини ритуалларга карата ихтирамлы мөнәсәбәт турында мәгълүмат урнаштыру | Башкарма комитет мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсенең массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү бүлеге | ел дәвамында | чаралар саны, берәмлек | 2 | 2 | 2 | 2 | финанслау таләп ителми |
| 19 | Шәһәр мәчетләрендәге атналык җомга намазлары формасында эчке конфессия мөнәсәбәтләрен мониторинглау | Башкарма комитет мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсенең җәмәгатьчелек белән элемтә бүлеге | атна саен | чаралар саны, берәмлек | 30 | 30 | 30 | 30 | финанслау таләп ителми |
| 20 | Экстремизм һәм террорчылыкны профилактикалау буенча «Экстремизмга – Юк» айлыгы үткәрү | Башкарма комитетның структур бүлекчәләре, террорчылыкка каршы комиссия, Башкарма | сентябрь ел саен | чаралар саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | финанслау таләп ителми |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге | | | | | | | | | |
| 21 | Экстремистик эчтәлекле мәгълүмати материалларны ачыклау предметына интернеттагы социаль челтәрләр мониторингын гамәлгә ашыру һәм хокук саклау органнары белән киңәшмәдә шул хакта хәбәр итү | Террорчылыкка каршы комиссия | ай саен | чаралар саны, берәмлек | 4 | 4 | 12 | 12 | финанслау таләп ителми | | |
| 22 | Югары һәм һөнәри белем бирү оешмаларының педагог-психологларын җәлеп итеп, этникара һәм конфессияара килешүнең формалашу дәрәҗәсен билгеләүгә юнәлдерелгән сораштыру үткәрүне тәэмин итү | Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе | уку елы дәвамында | чаралар саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | финанслау таләп ителми | | |
| 23 | Яр Чаллы шәһәрендәге РФ ФКХИ хезмәте белгечләрен җәлеп итеп, аерым затка яки затлар төркемнәренә карата дошманлык һәм нәфрәт уяту, шулай ук раса, милләт һәм дингә мөнәсәбәте буенча кешелек дәрәҗәсен кимсетү билгеләре булган мәгълүмати материалларга психология-лингвистика экспертизасы һәм тикшерүләре үткәрүне оештыру | Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге, шәһәрнең террорчылыкка каршы комиссиясе | кирәк булган саен | чаралар саны, берәмлек | - | - | - | 10 | Муниципаль бюджет | | |
| | | | | | | | | | - | - | 500,00 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2 бурыч. Белем бирү оешмаларының террорчылыкка каршы саклануын арттыру буенча чараларны тәэмин итү | | | | | | | | | | | |
| 24. | Гомуми белем бирү оешмаларында тревога сигнализациясе кнопкасын карап тоту һәм ведомстводан тыш саклау | Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе | ел саен | Гомуми белем бирү оешмаларының төзек видеокүзәтү системалары һәм тревога сигнализациясе кнопкалары белән тәэмин ителеше, % | 100 | 100 | 100 | 100 | Муниципаль бюджет | | |
| | | | | | | | | | 3608,4 | 3635,5 | 4126,5 |
| 25. | Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тревога сигнализациясе кнопкасын карап тоту һәм ведомстводан тыш саклау | Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе | ел саен | Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының төзек видеокүзәтү системалары һәм тревога сигнализациясе кнопкалары белән тәэмин ителеше, % | 100 | 100% | 100 | 100 | Муниципаль бюджет | | |
| | | | | | | | | | 8229,2 | 8397,4 | 8781,90 |
| | Барлыгы: | | | | | | | | 11907,5 | 12097,7 | 13478,4 |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

МУНИЦИПАЛЬНОЕ КАЗЕННОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ «ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН» ... УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Г.К. Әхмәтова